КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 март г.Казань № 161

Татарстан Республикасының төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары яисә аларның участоклары өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектларын килештерүне гамәлгә ашыручы органнар һәм оешмалар исемлеген һәм Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан муниципаль район, шәһәр округы яки шәһәр җирлеге территориясе яисә аларның өлешләре өчен, шулай ук уртак чикләре булган берничә муниципаль район, шәһәр округы яки шәһәр җирлеге территориясе өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемалары килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 29 декабрь, ФЗ-443 нче Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 ел, 20 декабрь, ТРЗ-103 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасының төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары яисә аларның участоклары өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен

оештыру проектларын килештерүне гамәлгә ашыручы органнар һәм оешмалар исемлеген;

Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан муниципаль район, шәһәр округы яки шәһәр җирлеге территориясе яисә аларның өлешләре өчен, шулай ук уртак чикләре булган берничә муниципаль район, шәһәр округы яки шәһәр җирлеге территориясе өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемалары килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 6 март, 161 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары яисә аларның участоклары өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектларын килештерүне гамәлгә ашыручы органнар һәм оешмалар исемлеге

1. «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе.

2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе (килешү буенча).

3. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе – юл сервисы объектларын урнаштыру, инженерлык коммуникацияләрен (корылмаларын) үткәрү һәм ремонтлау өлешендә.

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 6 март, 161 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан муниципаль район, шәһәр округы яки шәһәр җирлеге территориясе яисә аларның өлешләре өчен, шулай ук уртак чикләре булган берничә муниципаль район, шәһәр округы яки шәһәр җирлеге территориясе өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемалары килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеге

1. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе (килешү буенча).

2. Автомобиль юллары хуҗасы яисә юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемасы эшләнә торган муниципаль районнар, шәһәр округлары һәм шәһәр җирлекләре территориясе буенча үтә торган автомобиль юллары оператив идарәдә булган орган.

___